ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

18.06.2018 Казан ш. № 4-1/г

Татарстан Республикасы халкына озатыла торган табигый газга ваклап сату бәяләре урнаштыру турында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» 1999 елның 31 мартындагы 69-ФЗ номерлы Федераль законга, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең «Халыкка озатыла торган табигый газга ваклап сату бәяләрен көйләү буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2011 елның 27 октябрендәге боерыкка, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 нче Карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында Нигезләмәгә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы халкына озатыла торган табигый газга кубометрына 5,57 сум күләмендә ваклап сату бәясе куярга (ӨКСны исәпкә алып).

2. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасында халыкка озатыла торган табигый газга ваклап сату бәяләре урнаштыру турында» 2017 елның 6 июнендәге 4-1/г номерлы Карарының үз көчен югалтуын танырга.

3. Әлеге Карар Монополиягә каршы Федераль хезмәтнең «Газпром» ГАЖ һәм аның караган затлар тарафыннан алга таба халыкка сату өчен табыла торган газга күмәртәләп сату бәяләрен раслау турында»гы боерыгы үз көченә кергән көннән үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов